КАРАР (РЕШЕНИЕ)

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге составына керүче Явлаштау торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

28.03.2024 ел

№ 1

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан РеспубликасыЗаконының 35 статьясы нигезендә,Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Уставының 23 нче маддәсе, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Советының 17.12.2021 елның 28 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында " карарына таянып 2024 елның 28 мартында узган гражданнар җыенында «2024 нче елда Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Явлаштау торак пунктында балигъ булган, Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге составына керүче Явлаштау торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,0 (биш йөз ) сум күләмендә үзара салым кертүгә кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге максатларда файдаланырга:

-Явлаштау торак пунктында балалар мәйданчыгы кору(участокны планлаштыру, кече архитектура формаларын урнаштыру, щепа җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү)

- Явлаштау торак пунктында янгын гидрантларын урнаштыру ( Җир эшләре, тимер-бетон боҗралар урнаштыру, фасон өлешләрен урнаштыру,янгын гидрантларын урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү) дигән сораулар буенча 2023 елның 03 ноябендә узган халык җыены 1 карарында күрсәтелгән эш төрләрен түбәндәге эш төрләренә үзгәртергә:

-Торак пункт территориясен төзекләндерү (Явлаштау торак пунктында балалар мәйданчыгы төзү );

-Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү (Явлаштау торак пунктында янгын гидрантларын урнаштыру)

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган, гражданнар җыенына 266 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 139 кеше тавыш бирүдә катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 139 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1.Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге составына керүче Явлаштау торак пунктында халык җыенын үткән дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2.«Сез «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге составына керүче Явлаштау торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 29.11.2023 ел №1 карарына үзгәрешләр кертүгә, 29.11.2023 елгы 1 нче карарында күрсәтелгән эш төрләрен түбәндәге эш төрләренә үзгәртүгә:

-Торак пункт территориясен төзекләндерү (Явлаштау торак пунктында балалар мәйданчыгы төзү );

- Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү (Явлаштау торак пунктында янгын гидрантларын урнаштыру) ризамы», карарын кабул ителгән дип танырга.

3.Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/evlashtay адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге башлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында
рәислек итүче,
Явлаштау авыл
җирлеге башлыгы

Р.Х.Нуриев